Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре № 7

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Ишәле авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Чуаш Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 18 ноябрендә 10.00 сәгатькә мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Ишәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Ишәле авылы, Красноармейская ур., 6 нчы йорт.
2. 2020 елның 25 ноябрендә 10.00 сәгатькә мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Ишәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Ишәле авылы, Кызыл Армия ур., 6 нчы йорт.
*3.* Гражданнарның этаплап җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Ишәле авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:
1) Октябрь һәм Яңа урамнары;
*2)* Пионер һәм Красноармейская урамнары*.*
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2021 елда Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Ишәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, сугышта һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, 300 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:
- авыл эчендәге юлларга вак таш салу;

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
6. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны
авыл җирлеге башлыгы С.М. Егоров